**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яңа Иркәнәш торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 2 28 ноябрь 2025

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яңа Иркәнәш торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Яңа Иркәнәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Авыл көне үткәрү урынын чистарту, Яңа Иркәнәш торак пунктында эскәмияләр, будкалар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы ____________ И.З. Камалов

Совет Иркеняшского сельского поселения
ОГРН 1021605552697
ИНН 1628002756